| МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

12.08.2022 № 249

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы чикләрендә уза торган даими төбәкара маршрут буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикасына карата таләп билгеләү турында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законны һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы чикләрендә уза торган даими төбәкара маршруты буенча автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикасына карата 4 һәм аннан югары экологик классы таләбен билгеләргә.

2. Транспорт идарәсенең автомобиль транспорт бүлеге җитәкчесе

М.А.Захватовага әлеге Боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикаларын раслау турында» 2016 елның 18 июлендәге 221 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Транспорт идарәсе җитәкчесенә йөкләргә.

Министр Ф.М.Хәнифов